**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер, Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**«06» февраль 2023 ел** **№ 3**

**«Яңа Кенәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 № 34 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 04.08.2022 № 75 карары нигезендә, 14.11.2022 №1, 14.11.2022 №2, 14.11. 2022 №3, 15.11.2022 №4, 15.11.2022 №5, 16.11.2022 №6, 16.11.2022 №7, 17.11.2022 №8, 17.11.2022 № 9, 18.11.2022 №10 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымы чараларын җыю тәртибе турында» Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 № 34 карары белән расланган Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 һәм 4 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм түбәндәге адреслар буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында

урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет урамы, 10 нчы йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Сөрде авылы, Совет урамы, 48 нче йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин урамы, 17 нче йорт.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы                    Ә.Ә. Гайфуллин